**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№6572**
**23.11.2022**

«Балаларны мәктәпкәчә белем бирү программаларын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү оешмаларына исәпкә кую һәм җибәрү» муниципаль хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 41 статьясы нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. «Балаларны мәктәпкәчә белем бирү программаларын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү оешмаларына исәпкә кую һәм җибәрү» муниципаль хезмәте күрсәтүнең административ регламентын кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитет карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

1) «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программасын тормышка ашыра торган белем бирү оешмаларына (балалар бакчаларына) гаризалар кабул итү, балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 11 февралендәге 623 номерлы;

2) «Башкарма комитетның 2022 елның 11 февралендәге 623 номерлы карары белән расланган «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программасын тормышка ашыра торган белем бирү оешмаларына (балалар бакчаларына) гаризалар кабул итү, балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 7 ноябрендәге 6156 номерлы.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2022 елның 23 ноябрендәге
6572 номерлы карарына
кушымта

«Балаларны мәктәпкәчә белем бирү программаларын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү оешмаларына исәпкә кую һәм җибәрү»
муниципаль хезмәте күрсәтүнең
административ регламенты

## I. Гомуми нигезләмәләр

### Административ регламентның җайга салу предметы

«Балаларны мәктәпкәчә белем бирү программаларын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү оешмаларына исәпкә кую һәм җибәрү» муниципаль хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – административ регламент) муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфатын һәм аннан файдалану мөмкинлеген арттыру максатларында эшләнде, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында төп белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем бирүне оештыру буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда гамәлләр (административ процедуралар) стандартын, срокларын һәм эзлеклелеген билгели. Әлеге административ регламент «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 1 өлешнең 6 пункты, 2 өлеше, 67 статьясындагы 4.1 өлеше нигезендә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала.

### Гариза бирүчеләр даирәсе

1.1. Муниципаль хезмәттән файдалану өчен гариза бирүче булып 0 яшьтән 7 яшькә кадәрге баланың ата-анасы (законлы вәкиле) (алга таба – гариза бирүче) тора.

1.2. «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – ЕПГУ) (https://www.gosuslugi.ru/) һәм/яки региональ дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы (алга таба – РПГУ) аша муниципаль хезмәттән файдалану өчен гариза бирүче булып баланың «Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада Бердәм идентификация һәм аутентификация системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – ЕСИА) теркәлү процедурасын узуны тәмамлаган ата-анасы (законлы вәкиле) тора.

1.3. Мәктәпкәчә төп белем бирү программасын тормышка ашыра торган белем бирү оешмаларына (алга таба – Оешма) чираттан тыш урнашу хокукына ия:

судьяларның балалары;

прокурорларның һәм Россия Федерациясе Тикшерү комитеты хезмәткәрләренең балалары;

Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарның һәм аларга тиңләштерелгән категориядәге гражданнарның балалары;

террорчылык оешмаларын ачыклау һәм аларның эшчәнлеген булдырмау буенча махсус көчләрнең һәм Россия Федерациясенең Төньяк Кавказ регионы территориясендә террорчылыкка каршы операцияләр үткәрү буенча берләштерелгән гаскәрләр (көчләр)

төркеме төркемнәренең һәлак булган (хәбәрсез югалган), үлгән, инвалид булып калган хезмәткәрләренең һәм хәрби хезмәткәрләренең балалары;

Дагстан Республикасы территориясендә террорчылыкка каршы көрәштә турыдан-туры катнашкан һәм хезмәт бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә һәлак булган (хәбәрсез югалган), үлгән, инвалид булган хәрби хезмәткәрләрнең һәм эчке эшләр органнары, дәүләт янгынга каршы хезмәте, җинаять-башкарма системасы хезмәткәрләренең балалары;

Россия Федерациясе гражданнары тарафыннан Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә мобилизация буенча хәрби хезмәт узу чорында, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның балалары.

Оешмага беренче чиратта урнашу хокукына ия:

инвалид балалар һәм ата-анасының берсе инвалид булган балалар;

күп балалы гаилә балалары;

полиция хезмәткәренең балалары, шул исәптән хезмәт вазыйфаларын үтәүгә бәйле рәвештә имгәнү яки сәламәтлегенә башка зыян килү нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) полиция хезмәткәренең балалары; полициядә хезмәт вазыйфаларын үтәүгә бәйле рәвештә авыру нәтиҗәсендә үлгән полиция хезмәткәренең балалары; хезмәт вазыйфаларын үтәүгә бәйле рәвештә алынган һәм алга таба полициядә хезмәт итү мөмкинлеге бирми торган имгәнү яки сәламәтлегенә башка зыян килү нәтиҗәсендә полиция хезмәтеннән азат ителгән Россия Федерациясе гражданының балалары; хезмәт вазыйфаларын үтәүгә бәйле рәвештә имгәнү яки сәламәтлегенә башка зыян килү нәтиҗәсендә яисә полициядә хезмәт итү чорында алга таба полициядә хезмәт итү мөмкинлеге бирми торган авыру нәтиҗәсендә полиция хезмәтеннән азат ителгәннән соң бер ел эчендә үлгән Россия Федерациясе гражданының балалары; Россия Федерациясе гражданы, полиция хезмәткәре тәрбиясендә булучы (булган) балалар;

хәрби хезмәткәрләрнең балалары;

махсус исемнәргә ия булган һәм җинаять-башкарма системасы учреждениеләрендә һәм органнарында, Дәүләт янгынга каршы хезмәтнең федераль янгынга каршы хезмәтендә, Россия Федерациясе таможня органнарында хезмәт итүче, шул исәптән хезмәт вазыйфаларын үтәүгә бәйле рәвештә имгәнү яки сәламәтлегенә башка зыян килү нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән); хезмәт итү чорында алынган авыру нәтиҗәсендә үлгән; хезмәт вазыйфаларын үтәүгә бәйле рәвештә алынган һәм алга таба хезмәт итү мөмкинлеге бирми торган имгәнү яки сәламәтлегенә башка зыян килү нәтиҗәсендә полиция хезмәтеннән азат ителгән; хезмәт вазыйфаларын үтәүгә бәйле рәвештә имгәнү яки сәламәтлегенә башка зыян килү нәтиҗәсендә яисә хезмәт итү чорында алга таба хезмәт итү мөмкинлеге бирми торган авыру нәтиҗәсендә хезмәтеннән азат ителгәннән соң бер ел эчендә үлгән Россия Федерациясе гражданының балалары; Россия Федерациясе гражданы, хезмәткәре тәрбиясендә булучы (булган) балалар.

Бер гаиләдә яшәүче һәм яшәү урыны уртак булган балалар, мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программалары буенча белем алу өчен, аларның ир һәм (яки) кыз туганнары укый торган Оешмаларга өстенлекле кабул итү хокукына ия.

## Муниципаль хезмәт күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (аларның реквизитларын һәм рәсми бастырып чыгару чыганакларын күрсәтеп) «Федераль дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында, ЕПГУда һәм/яки РПГУда тиешле бүлекләрдә, Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының рәсми сайтында урнаштырыла:

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон;

Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының «Укучыларны мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган бер оешмадан тиешле дәрәҗәдәге һәм юнәлешле белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган башка оешмаларга күчерү тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2015 елның 28 декабрендәге 1527 номерлы приказы (ата-ана (законлы вәкил) инициативасы буенча муниципаль белем бирү оешмасына күчерү өлешендә);

Россия Мәгариф министрлыгының «Мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча укырга кабул итү тәртибен раслау турында» 2020 елның 15 маендагы 236 номерлы боерыгы;

Россия Мәгариф министрлыгының «Төп гомуми белем бирү программалары – мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2020 елның 31 июлендәге 373 номерлы приказы (аерым төркемнәрдә яки аерым белем бирү оешмаларында балалар саны өлешендә);

Федераль законнарда каралганча муниципаль хезмәтне чираттан тыш (беренче чиратта) күрсәтүгә хокук өлешендә:

Россия Федерациясенең «Чернобыль АЭС һәлакәте нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» 1991 елның 15 маендагы 1244-1 номерлы Законы;

Россия Федерациясенең «Россия Федерациясе прокуратурасы турында» 1992 елның 17 гыйнварындагы 2202-1 номерлы Законы;

Россия Федерациясенең «Россия Федерациясендә судьялар статусы турында» 1992 елның 26 июнендәге 3132-1 номерлы Законы;

«Хәрби хезмәткәрләр статусы турында» 1998 елның27 маендагы 76-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Россия Федерациясе Тикшерү комитеты турында» 2010 елның 28 декабрендәге 403-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Полиция турында» 2011 елның 7 февралендәге 3-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Кайбер федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләренең социаль гарантияләре һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2012 елның 30 декабрендәге 283-ФЗ номерлы Федераль закон;

Россия Федерациясе Президентының «Гаиләләргә социаль ярдәм чаралары турында» 1992 елның 5 маендагы 431 номерлы Указы;

Россия Федерациясе Президентының «Инвалидларга өстәмә дәүләт ярдәме чаралары турында» 1992 елның 2 октябрендәге 1157 номерлы Указы;

Россия Федерациясе Югары Советының «Чернобыль АЭС һәлакәте нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» РСФСР Законының гамәлдә булуын аеруча куркыныч янаган бүлекчәләрдәге гражданнарга тарату хакында» 1991 елның 27 декабрендәге 2123-1 номерлы карары;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дагстан Республикасы территориясендә террорчылыкка каршы көрәштә турыдан-туры катнашкан һәм хезмәт бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә һәлак булган (хәбәрсез югалган) һәм үлгән, инвалид булып калган эчке эшләр органнары, дәүләт янгынга каршы хезмәте, җинаять-үтәтү системасы хезмәткәрләренең һәм хәрби хезмәткәрләрнең гаиләләре әгъзаларын социаль яклау буенча өстәмә чаралар турында» 1999 елның 25 августындагы 936 номерлы карары;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясенең Төньяк Кавказ регионы территориясендә контртеррорчылык операцияләрендә катнашучы һәм хокук тәртибен һәм иҗтимагый иминлекне тәэмин итүче хәрби хезмәткәрләргә һәм

федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләренә өстәмә гарантияләр һәм компенсацияләр турында» 2004 елның 9 февралендәге 65 номерлы карары;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Көньяк Осетия һәм Абхазия территорияләрендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарының иминлеген тәэмин итү һәм яклау бурычларын үтәүдә катнашучы хәрби хезмәткәрләрне һәм федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләрен социаль яклауны көчәйтү буенча өстәмә чаралар турында» 2008 елның 12 августындагы 587 номерлы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә өстәмә ярдәм чаралары турында» 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы карары.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында мәгълүмат бирү тәртибенә таләпләр

1.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү гамәлгә ашырыла:

1) гариза бирүчене Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты мәгариф идарәсенең мәктәпкәчә белем бирү бүлегендә (алга таба – вәкаләтле орган) яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәктә (алга таба – күпфункцияле үзәк) шәхсән кабул иткәндә;

2) телефон аша Вәкаләтле органда яки күпфункцияле үзәктә;

3) язмача, шул исәптән электрон почта, гомуми файдаланудагы почта элемтәсе (алга таба – почта элемтәсе) ярдәмендә;

4) ачык һәм һәркем файдалана алырлык мәгълүмат формасында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән:

ЕПГУда һәм/яки РПГУда;

Вәкаләтле органның рәсми сайтында (http://nabchelny.ru/user/67994);

Вәкаләтле органның яки күпфункцияле үзәкнең мәгълүмат стендларында мәгълүмат урнаштыру юлы белән.

1.6. Мәгълүмат бирү түбәндәгеләргә кагылышлы мәсьәләләр буенча гамәлгә ашырыла:

муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза бирү ысуллары;

муниципаль хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итәргә кирәкле Вәкаләтле орган һәм күпфункцияле үзәкләр адреслары;

Вәкаләтле органның (Вәкаләтле орган структур бүлекчәләренең) һәм күпфункцияле үзәкләрнең эше турында белешмә мәгълүмат;

муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары;

муниципаль хезмәт күрсәтү турында һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында гаризаны карап тикшрү барышы хакында мәгълүматлар алу тәртибе;

муниципаль хезмәт күрсәткәндә вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм алар тарафыннан кабул ителә торган карарларга судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе.

Муниципаль хезмәт күрсәтү һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлегенә кертелгән муниципаль хезмәтләр күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат алу бушлай гамәлгә ашырыла.

1.7. Гариза бирүче телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон буенча) Вәкаләтле органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәкнең консультация бирүне гамәлгә ашыручы хезмәткәре кызыксындырган мәсьәләләр буенча җентекләп һәм әдәпле (корректлы) рәвештә гариза бирүчеләргә хәбәр итә.

Телефон звоногына җавап гариза бирүче шалтыраткан органның исеме, телефон звоногын кабул иткән белгечнең вазыйфасы турындагы мәгълүматтан башлана.

Әгәр Вәкаләтле органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк хезмәткәре мөстәкыйль рәвештә җавап бирә алмаса, телефон звоногы башка вазыйфаи затка адресланырга (күчерелергә) яки мөрәҗәгать иткән затка тиешле мәгълүматны алырга мөмкин булган телефон номеры хәбәр ителергә тиеш. Әгәр җавапны әзерләү озак вакыт таләп итсә, ул гариза бирүчегә алдагы гамәлләрнең түбәндәге вариантларының берсен тәкъдим итә: мөрәҗәгатьне язма рәвештә бәян итәргә һәм Вәкаләтле органның, күпфункцияле үзәкнең электрон почтасы буенча яки почта элемтәсе аша аша җибәрергә; консультацияләр өчен башка вакыт билгеләргә; шәхсән килергә.

Вәкаләтле органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк хезмәткәре муниципаль хезмәт күрсәтүнең стандарт процедуралары һәм шартлары кысаларыннан чыга торган һәм кабул ителә торган карарга турыдан-туры яки читләтеп йогынты ясый торган мәгълүмат бирүне гамәлгә ашырырга хокуклы түгел.

Телефон буенча мәгълүмат бирү 10 минуттан да артырга тиеш түгел.

Мәгълүмат бирү гражданнарны кабул итү графигы нигезендә гамәлгә ашырыла.

1.8. Язма мөрәҗәгать буенча Вәкаләтле органның муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк хезмәткәре «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә административ регламентның 1.6 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча гражданга язма рәвештә җентекләп аңлата.

1.9. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 24 октябрендәге 861 номерлы карары белән расланган «Федераль дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәдә каралган мәгълүматлар ЕПГУда урнаштырыла.

Муниципаль хезмәт күрсәтү сроклары, тәртибе һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар турында мәгълүматтан файдалану, гариза бирүче тарафыннан нинди дә булса таләпләрне үтәмичә, шул исәптән аны гариза бирүченең техник чараларына урнаштыру түләү алу, теркәлү яки авторлаштыруны, яки аларга персональ мәгълүматлар бирүне күздә тотучы программа белән тәэмин итү хокукына ия зат белән лицензияле яки башка килешү төзүне таләп итә торган программа тәэминатыннан файдаланмыйча гамәлгә ашырыла.

1.10. Вәкаләтле органның рәсми сайтында, муниципаль хезмәт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү урыннарындагы стендларда һәм күпфункцияле үзәктә түбәндәге белешмә мәгълүмат урнаштырыла:

Вәкаләтле органның һәм аның муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы структур бүлекчәләренең урнашу урыны һәм эш графигы турында, шулай ук күпфункцияле үзәкләр турында;

Вәкаләтле органның муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы структур бүлекчәләренең, шулай ук күпфункцияле үзәкләрнең белешмә телефоннары, шул исәптән автоинформатор телефоны номеры (булган очракта);

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Вәкаләтле органның рәсми сайты, шулай ук электрон почта адресы һәм (яки) кире элемтә формасы.

1.11. Вәкаләтле органның көтү залларында муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибен җайга сала торган норматив хокукый актлар, шул исәптән гариза бирүченең таләбе буенча танышу өчен аңа бирелә торган административ регламент урнаштырыла.

1.12. Күпфункцияле үзәк бинасында муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат урнаштыру, административ регламентта билгеләнгән мәгълүмат бирүгә таләпләрне исәпкә алып, күпфункцияле үзәк һәм Вәкаләтле орган арасында төзелгән килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

1.13. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында гаризаны карап тикшерү барышы турында мәгълүмат тарафыннан ЕПГУда һәм/яки РПГУда гариза бирүченең шәхси кабинетында, шулай ук Вәкаләтле органның тиешле структур бүлекчәсендә, күпфункцияле үзәкләрдә, гариза бирүче шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, телефон аша, электрон почта яки почта элемтәсе аша алынырга мөмкин.

## II. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

### Муниципаль хезмәтнең исеме

2.1. «Балаларны мәктәпкәчә белем бирү программаларын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү оешмаларына исәпкә кую һәм җибәрү» муниципаль хезмәте.

### Муниципаль хезмәт күрсәтүче җирле үзидарә органы (оешма) исеме

2.2. Муниципаль хезмәт Вәкаләтле орган – Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты мәгариф идарәсенең мәктәпкәчә белем бирү бүлеге тарафыннан күрсәтелә.

2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнаша: Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты мәгариф идарәсенең мәктәпкәчә белем бирү бүлеге. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә Вәкаләтле орган тууны теркәү турында таныклыкны сораганда «Граждан хәле актларын теркәү идарәсе» муниципаль казна учреждениесе белән хезмәттәшлек итә.

2.4. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә Вәкаләтле органга гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлегенә кертелгән хезмәтләрдән файдаланудан тыш, муниципаль хезмәттән файдалану өчен кирәкле һәм башка дәүләт органнарына һәм оешмаларга мөрәҗәгать итү белән бәйле гамәлләрне, шул исәптән килештерүләрне гамәлгә ашыруны таләп итү тыела.

### Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау

2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып тора:

муниципаль белем бирү оешмасында урын бирелүгә мохтаҗларны исәпкә кую (арадаш нәтиҗә) һәм муниципаль белем бирү оешмасына җибәрү (төп нәтиҗә).

2.5.1. Административ регламентка 1 нче кушымтда һәм 2 нче кушымтада каралган форма буенча исәпкә кую (арадаш нәтиҗә) өлешендә муниципаль хезмәт күрсәтү турында карар.

2.5.2. Административ регламентка 3 нче кушымтада һәм 4 нче кушымтада каралган форма буенча муниципаль белем бирү оешмасына җибәрү (төп нәтиҗә) өлешендә муниципаль хезмәт күрсәтү турында карар.

2.5.3. Административ регламентка 5 нче кушымтада һәм 6 нчы кушымтада каралган форма буенча исәпкә кую (арадаш нәтиҗә) өлешендә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар.

### Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген исәпкә алып, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату срогы, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) срогы

2.6. Вәкаләтле орган административ регламентның 2.5.1 яки 2.5.3 пунктларында күрсәтелгән нәтиҗәләрне, гариза һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар теркәлгән көннән башлап 7 эш көне эчендә, гаризада күрсәтелгән ысул белән яки, гариза электрон формада бирелгән очракта, ЕПГУда

һәм/яки РПГУда шәхси кабинетка мәгълүмат җибәрү юлы белән гариза бирүчегә җибәрә.

Вәкаләтле орган, гаризада күрсәтелгән кабул итүнең теләгән датасын исәпкә алып, муниципаль белем бирү оешмасына җибәрү турында документ расланган көннән башлап 1 көн эчендә административ регламентның 2.5.2 пунктында күрсәтелгән нәтиҗәне гариза бирүчегә җибәрә.

2.7. Муниципаль хезмәтне туктату срогы каралмаган.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен
норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле
документларның һәм белешмәләрнең тулы исемлеге

2.8. Муниципаль хезмәттән файдалану өчен гариза бирүче тапшыра:

2.8.1. Административ регламентка 7 нче кушымта нигезендә электрон формада яки 8 нче кушымта нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү турында кәгазь төрдәге гариза һәм административ регламентның 2.8.2.-2.8.8 пунктлары нигезендә документлар, шул исәптән гаризага теркәлә торган электрон документлар рәвешендә. Гариза ЕПГУ һәм/яки РПГУ аша җибәрелгән очракта, гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, ЕПГУда һәм/яки РПГУда интерактив форманы тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.8.2. Гариза бирүченең шәхесен раслый торган документ. Гариза ЕПГУ һәм/яки РПГУ аша җибәрелгәндә ЕСИАда исәп язмасын булдырганда һәм раслаганда кулланучы тарафыннан күрсәтелгән гариза бирүченең шәхесен раслаучы документ турындагы мәгълүматлар тапшырыла. Күрсәтелгән мәгълүматлар, СМЭВдан файдаланып, запрос җибәрү юлы белән тикшерелергә мөмкин.

2.8.3. Гариза бирүченең Россия Федерациясендә тору хокукын раслый торган документ(-лар), баланың шәхесен таныклый торган һәм бала хокукларын яклау законлылыгын раслый торган документ(-лар) (гариза бирүче – чит ил гражданы яисә гражданлыгы булмаган зат өчен).

2.8.4. Опека билгеләүне раслый торган документ (кирәк булганда).

2.8.5. Психологик-медик-педагогик комиссия документы (кирәк булганда).

2.8.6. Сәламәтләндерү юнәлешендәге төркемдә белем алуга ихтыяҗны раслый торган документ (кирәк булганда).

2.8.7. Гражданнарның аерым категорияләренең һәм аларның гаиләләренең махсус ярдәм чараларына (гарантияләргә) хокуклары булуны раслый торган документ (кирәк булганда).

2.8.8. Баланың тору урыны, фактта яшәү урыны турында мәгълүматлар булган документ (баланы яшәү урыны буенча яки беркетелгән территориядә тору урыны буенча теркәү турында таныклык булмаганда).

Кәгазь төрдә бирелгән гаризада шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен җибәрүнең түбәндәге ысулларының берсе күрсәтелә:

телефон, электрон почта аша хәбәр итү рәвешендә;

Вәкаләтле органда, күпфункцияле үзәктә электрон документның кәгазьдә бастырылган һәм/яки гаризада күрсәтелгән почта адресы буенча җибәрелгән нөсхәсе рәвешендә.

2.9. Гариза бирүче, җибәрү өчен кәгазь төрдә бирелгән гариза буенча мәгълүмат алу турында гаризаны ЕПГУда рәсмиләштергәндә, хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен өстәмә рәвештә ЕПГУда алырга мөмкин.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы башка органнар һәм оешмалар карамагындагы документларның һәм мәгълүматларның тулы исемлеге

2.10. Мөрәҗәгать иткән очракта, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы башка органнар һәм оешмалар карамагындагы документлар һәм мәгълүматлар исемлеге:

- Россия Федерациясе территориясендә бала туу турында мәгълүматлар;
- баланы яшәү урыны буенча яки беркетелгән территориядә тору урыны буенча теркәү турында мәгълүматлар яки баланың тору урыны, фактта яшәү урыны турында мәгълүматлар булган документлар.

2.11. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән таләп итү тыела:

2.11.1. Тапшыру яки гамәлгә ашыру, муниципаль хезмәт күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда каралмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыру яки гамәлләрне башкару.

2.11.2. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, Яр Чаллы шәһәренең муниципаль хокукый актлары нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтүче органнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яки) дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары буйсынуындагы муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмалар карамагында булган документларны һәм мәгълүматны тапшыру, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) 7 статьясындагы 6 өлешендә күрсәтелгән документлардан тыш.

2.11.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән беренче тапкыр баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат тапшыруны, түбәндәге очраклардан тыш:

- муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны беренче тапкыр биргәннән соң, муниципаль хезмәт күрсәтүгә кагылышлы норматив хокукый актларның таләпләре үзгәрү;
- муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризада һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән беренче тапкыр баш тартканнан соң гариза бирүче тарафыннан тапшырылган һәм элек бирелгән документлар комплектына кертелмәгән документларда хаталар булу;
- документларның гамәлдә булу срогы тәмамлану яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән беренче тапкыр баш тартканнан соң мәгълүмат үзгәрү;
- муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән беренче тапкыр баш тартканда, Вәкаләтле орган вазыйфаи затының, хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешма хезмәткәренең хаталы яки хокукка каршы гамәленең (гамәл кылмавының) докуметлар белән расланган факты (билгеләре) ачыклану, дәүләт (муниципаль) хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда, бу хакта Вәкаләтле орган җитәкчесенең, күпфункцияле үзәк җитәкчесенең яисә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешма җитәкчесенең имзасы белән язма рәвештә гариза бирүчегә хәбәр ителә, шулай ук тудырылган уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә.

Гариза кәгазь төрдә биреләндә, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.12. Гариза кәгазь төрдә бирелгәндә, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны карап тикшерүгә кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булып тора:

1) административ регламентның 2.8 пункты нигезендә тулы булмаган мәгълүмат бирү (гариза бирүчедән тулы булмаган документлар комплекты);

2) гариза бирүче тарафыннан бирелгән документларда текстны Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә расланмаган чистартулар һәм төзәтүләр бар;

3) документларда муниципаль хезмәт күрсәтү өчен документлардагы мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмдә файдаланырга мөмкинлек бирми торган кимчелекләр бар;

4) тапшырылган документлар яки мәгълүматлар муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән вакыткаа үз көчен югалткан (гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен таныклый торган документ, муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап күрсәтелгән зат мөрәҗәгать иткән очракта).

Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату һәм баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.13. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.

2.14. Исәпкә кую (арадаш нәтиҗә) өлешендә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:

гариза бирүче хезмәт күрсәтү хокукына ия затлар категориясенә туры килми;

- административ регламентның 2.8 пункты нигезендә дөрес булмаган мәгълүмат бирелү;

- тапшырылган документлар яки мәгълүматлар хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итү вакытына үз көчен югалткмн (хезмәт күрсәтүне сорап күрсәтелгән зат мөрәҗәгать иткән очракта, гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ);

- запрос формасында, шул исәптән ЕПГУда запросның интерактив формасында мәҗбүри кырлар дөрес тутырылмау, (дөрес түгел, тулы түгел, яисә дөрес тутырылмау) (гариза электрон төрдә бирелгәндә);

- тулы булмаган мәгълүмат, шул исәптән тулы булмаган документлар комплекты бирелү (гаризаны электрон рәвештә биргәндә).

Җибәрү (төп нәтиҗә) өлешендә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнар һәм оешмалар тарафыннан бирелә торган документ (документлар) турында мәгълүматлар

2.15. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр юк.

Муниципаль хезмәт күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре

2.16. Муниципаль хезмәт түләүсез күрсәтелә.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп, мондый түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре

2.17. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр юк.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә һәм, гаризаны кәгазь төрдә биргән очракта, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы

2.18. Вәкаләтле органда яки күпфункцияле үзәктә муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтүнең арадаш нәтиҗәсен алганда, чиратта көтүнең максималь срогы 15 минуттан артмый.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны теркәү срогы һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада

2.19. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризалар, гариза һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар алынган көннән башлап 1 эш көне эчендә Вәкаләтле органда теркәлергә тиеш.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, гариза кәгазь төрдә бирелгәндә, Вәкаләтле орган, җитешсезлекләрне төзәтү срогын исәпкә алып, җитешсезлекләрне төзәтү өчен билгеләнгән соңгы көннән соң килүче бер эш көненнән дә соңга калмыйча, әлеге административ регламентка 9 нчы кушымтада китерелгән форма буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карарны гариза бирүчегә җибәрә.

Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган бүлмәләргә таләпләр

2.20. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле кәгазь төрдәге гаризаларны һәм документларны кабул итү, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен кәгазь төрдә бирү гамәлгә ашырыла торган административ биналарның урнашу урыны, җәмәгать транспорты тукталышларыннан җәяү килү мөмкинлегеннән чыгып, гражданнар өчен уңайлыкларны тәэмин итәргә тиеш.

Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча кабул итү һәм нәтиҗәләрне бирү бүлмәсе урнашкан бина (төзелмә) янында стоянка (парковкалар) оештыру мөмкинлеге булган очракта, гариза бирүчеләрнең шәхси автомобиль транспорты өчен стоянка (парковка) оештырыла. Стоянкадан (парковкадан) файдаланган өчен, гариза бирүчеләрдән түләү алынмый.

Инвалидларның махсус автотранспорт чараларын стоянкага (парковкага) кую өчен, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, I, II төркем инвалидлар, шулай ук III төркем инвалидлар тарафыннан идарә ителә торган транспорт чараларын һәм мондый инвалидларны һәм (яки) инвалид балаларны йөртүче транспорт чараларын бушлай кую өчен кимендә 10% урын (ләкин бер урыннан ким түгел) бүлеп бирелә.

Гариза бирүчеләрнең, шул исәптән инвалид колясказарында хәрәкәтләнүче, муниципаль хезмәт күрсәтелә торган бинага һәм бүлмәгә тоткарлыксыз керүен тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турында законнары нигезендә пандуслар, тоткычлар, тактиль (контраст) кисәтү элементлары, инвалидларга тоткарлыксыз керү һәм хәрәкәт итү мөмкинлеген тәэмин итә торган башка махсус җайланмалар белән җиһазландырыла.

Вәкаләтле орган бинасына үзәк керү урыны түбәндге мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмати табличка (элмә такта) белән җиһазландырылырга тиеш:

исем;

урнашу урыны һәм юридик адресы;

эш режимы;

кабул итү графигы;

белешмәләр өчен телефон номерлары.

Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган бүлмәләр санитар-эпидемиологик кагыйдәләргә һәм нормативларга туры килергә тиеш.

Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган бүлмәләр түбәндәгеләр белән җиһазландырыла:

янгынга каршы система һәм янгын сүндерү чаралары;

гадәттән тыш хәл барлыкка килү турында хәбәр итү системасы;

беренче медицина ярдәме күрсәтү чаралары; килүчеләр өчен бәдрәф бүлмәләре.

Гариза бирүчеләрнең көтү залы, саны факттагы йөкләнештән һәм аларны бүлмәдә урнаштыру мөмкинлекләреннән чыгып билгеләнә торган урындыклар, эскәмияләр, шулай ук мәгълүмат стендлары белән җиһазландырыла.

Мәгълүмат стендында урнаштырылган материалларның текстлары, иң мөһим урыннарны ярым калын шрифт белән билгеләп, төзәтүләрсез, уку өчен уңайлы шрифт белән бастырыла.

Гаризалар тутыру өчен урыннар урындыклар, өстәлләр (стойкалар), гаризалар бланкалары, язу әсбаплары белән җиһазландырыла.

Гариза бирүчеләрне кабул итү урыннары түбәндәгеләр күрсәтелгән мәгълүмати табличкалар (элмә такталар) белән җиһазландырыла:

кабинет номеры һәм бүлекнең исеме;

документларны кабул итү өчен җаваплы зат вазыйфасы;

гариза бирүчеләрне кабул итү графигы.

Документлар кабул итү өчен һәр җаваплы затның эш урыны, кирәкле мәгълүмат базаларына керү мөмкинлеге булган персональ компьютер, бастыру җайланмасы (принтер) һәм күчермә ясау җайланмасы булган белән җиһазландырылырга тиеш.

Документлар кабул итү өчен җаваплы затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) һәм вазыйфасы күрсәтелгән өстәл табличкасы булырга тиеш.

Инвалидларга муниципаль хезмәт күрсәтелгәндә түбәндәгеләр тәэмин ителә:

муниципаль хезмәт күрсәтелә торган объектка (бинага, бүлмәгә) тоткарлыксыз керү мөмкинлеге;

муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналар һәм бүлмәләр урнашкан территория буенча, шул исәптән кресло-коляскадан файдаланып мөстәкыйль хәрәкәт итү, шулай ук мондый объектларга керү һәм алардан чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге;

күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясе нык бозылган инвалидларны озатып йөрү;

инвалидларның яшәеш мөмкинлекләре чикле булуны исәпкә алып, аларның муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга һәм бүлмәләргә тоткарлыксыз керүен һәм муниципаль хезмәттән файдалануын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөрткечләрне тиешенчә урнаштыру;

ишетә һәм күрә торган мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны рельефлы-нокталы Брайль шрифтында башкарылган билгеләр белән кабатлау;

сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;

юл күрсәтүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ булганда, аны муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган объектларга (биналарга, бүлмәләргә) кертү; инвалидларга муниципаль хезмәттән башка затлар белән бертигез файдалануга комачаулаучы каршылыкларны үтүдә ярдәм күрсәтү.

Муниципаль хезмәттән файдалану мөмкинлеге һәм сыйфат күрсәткечләре

2.21. Муниципаль хезмәттән файдалану мөмкинлегенең төп күрсәткечләре булып тора:

гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә (шул исәптән «Интернет» челтәрендә), массакүләм мәгълүмат чараларында муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе, сроклары һәм барышы турында тулы һәм аңлаешлы мәгълүмат булу;

муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән ЕПГУдан һәм/яки РПГУдан файдаланып;

гариза бирүче тарафыннан муниципаль белем бирү оешмасында урын бирү эзлеклелеге турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән ЕПГУдан һәм/яки РПГУдан файдаланып.

2.22. Муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфатының төп күрсәткечләре булып тора:

муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентта билгеләнгән стандарты нигезендә, аның үз вакытында күрсәтелүе; муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затлар белән гражданның үзара хезмәттәшлегенең минималь мөмкин булган саны; хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм аларның гариза бирүчеләргә карата әдәпсез (игътибарсыз) мөнәсәбәтенә нигезле шикаятьләр булмау;

Вәкаләтле орган тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтү процессында билгеләнгән срокларда җитешсезлекләр булмау;

Вәкаләтле органның, аның вазыйфаи затларының муниципаль хезмәт күрсәткәндә кабул ителә торган (кылынган) карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) дәгъва белдерү турында гаризалар булму (аларны карау йомгаклары буенча гариза бирүчеләрнең таләпләрен канәгатьләндерү (өлешчә канәгатьләндерү) турында карарлар чыгарылган).

Башка, шул исәптән күпфункцияле үзәкләрдә муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен, экстерриториаль принцип буенча муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен һәм электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә алган таләпләр

2.23. Экстерриториаль принцип буенча муниципаль хезмәт күрсәтү ЕПГУ һәм/яки РПГУ ярдәмендә гаризалар бирү һәм күпфункцияле үзәктә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алу мөмкинлеген тәэмин итү өлешендә гамәлгә ашырыла.

2.24. Гариза бирүчеләргә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле гаризаны, документларны һәм мәгълүматларны ЕПГУ һәм/яки РПГУ ярдәмендә электрон рәвештә җибәрү мөмкинлеге тәэмин ителә.

Муниципаль хезмәттән файдалану өчен, гариза бирүче ЕСИАда расланган исәп язмасы булган шәхси зат (физик зат) ролендә ЕПГУда һәм/яки РПГУда авторизацияләнергә, муниципаль хезмәт исемен күрсәтергә һәм тәкъдим ителгән интерактив гариза формасын тутырырга тиеш.

Гариза гариза бирүченең гади электрон имзасы белән имзалана һәм СМЭВ ярдәмендә Вәкаләтле органга җибәрелә. Муниципаль хезмәтнең электрон формасы вәкаләтле органның (оешманың) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән таныкланган 2.8.3 һәм 2.8.8 пунктларында каралган документларны электрон рәвештә беркетү мөмкинлеген күздә тота.

Административ регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән муниципаль хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәләре, ЕПГУда һәм/яки РПГУда гариза бирүченең шәхси кабинетына гариза буенча белдерүләр формасында җибәрелә.

Гариза ЕПГУ һәм/яки РПГУ аша җибәрелгән очракта, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе шулай ук гариза бирүчегә Вәкаләтле органда, күпфункцияле үзәктә кәгазь төрдә бирелергә мөмкин.

2.25. 2.8.3, 2.8.8 пунктларында каралган электрон документларны ЕПГУ аша тапшырганда, мондый документлар pdf форматында бирелә.

Электрон документлар түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

- документны һәм документтагы битләр санын идентификацияләү мөмкинлеге;

- өлешләр, бүлекләр, кисәкләр (кисәкчәләр) буенча структурлаштырылган һәм эчтәлек буенча һәм (яисә) тексттагы рәсемнәргә һәм таблицаларга күчүне тәэмин итә торган мәгълүматлар һәм билгеләрне үз эченә алган документлар өчен.

## III. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон формада башкару үзенчәлекләре

### Формасына бәйсез рәвештә, административ процедураларның тулы исемлеге

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

гаризаны һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итү һәм теркәү; СМЭВ ярдәмендә мәгълүматлар алу;

документларны һәм белешмәләрне карап тикшерү; карар кабул итү; арадаш нәтиҗәне бирү;

муниципаль хезмәтнең төп нәтиҗәсен юридик әһәмияткә ия язмалар реестрына кертү.

Административ процедуралар тасвирламасы административ регламентка 10 нчы кушымтада тәкъдим ителгән.

### ЕПГУ һәм/яки РПГУ аша электрон формада муниципаль хезмәт күрсәткәндә административ процедуралар (гамәлләр) исемлеге

3.2. Муниципаль хезмәтне электрон формада күрсәткәндә гариза бирүчегә өстәмә рәвештә түбәндәгеләр тәэмин ителә:

электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат алу; электрон формада гариза формалаштыру;

электрон формадагы гаризаны карап тикшерү барышы турында мәгълүматлар алу; гариза бирүченең запросы буенча башка формаларда бирелгән гаризаны карап тикшерү барышы турында ЕПГУда мәгълүматлар алу мөмкинлеге; муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфатын бәяләүне гамәлгә ашыру; Вәкаләтле орган карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) яисә муниципаль хезмәт күрсәтүче Вәкаләтле орган вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү.

### Хезмәт күрсәтү формасына бәйсез рәвештә административ процедураларны (гамәлләрне) башкару тәртибе

3.3. Гаризаны формалаштыру.

Гариза ЕПГУда һәм/яки РПГУда электрон рәвештә формалаштырылырга яки кәгазь төрдә бирелергә мөмкин.

Электрон формада гариза формалаштыру гаризаны кәгазь төрдә бирүне таләп итми.

Гаризаны электрон формада формалаштырганда, гариза бирүче гаризаның электрон формасының һәр кырын тутырганнан соң, формат-логик тикшерү гамәлгә ашырыла. Гаризаның электрон формасындагы дөрес тутырылмаган кыр ачыкланганда гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны мәгълүмати хәбәр юлы белән бетерү тәртибе турында гаризаның электрон формасында ук хәбәр ителә.

Гаризаны ЕПГУда һәм/яки РПГУдаа формалаштырганда гариза бирүчегә тәэмин ителә:

- кулланучының теләге буенча теләсә кайсы вакытта, шул исәптән күрсәткечләрне гаризаның электрон формасына кертү хаталары барлыкка килгәндә һәм кабат кертү өчен кире кайтканда, гаризаның электрон формасына элек кертелгән күрсәткечләрне саклап калу мөмкинлеге;

- гариза бирүченең профилендә ЕСИАга урнаштырылган мәгълүматлар нигезендә гаризаның электрон формасындагы кырларны автомат рәвештә тутыру мөмкинлеге;

- элек кертелгән мәгълүматны югалтмыйча, электрон форманы тутыруның теләсә кайсы этабына кайту мөмкинлеге;

- гариза бирүченең ЕПГУда һәм/яки РПГУда элек бирелгән гаризаларына ЕПГУда һәм/яки РПГУда керү мөмкинлеге.

ЕПГУда һәм/яки РПГУда формалаштырылган гариза СМЭВ ярдәмендә мәктәпкәчә белем алу мөмкинлегенең региональ мәгълүмат системасына (алга таба – РГИС ДДО) җибәрелә.

3.4. РГИС ДДОга кергәннән соң электрон гариза, Вәкаләтле органның гаризаны кабул итү һәм теркәү өчен җаваплы вазыйфаи заты (алга таба – җаваплы вазыйфаи зат) өчен ачык була. Шул ук вакытта ЕПГУда һәм/яки РПГУда гариза бирүчегә «Гариза мәктәпкәчә белем алу мөмкинлегенең региональ системасына тапшырылды. Гариза Порталда теркәлде» (гаризаны теркәү датасы һәм вакыты түбәндәге форматта: ДД.ММ.ГГГГ чч:мм:сс) номер белән (региональ мәгълүмат системасында гаризаның уникаль номеры). Гаризаның карап тикшерелүен 7 көн эчендә көтегез» дигән белдерү җибәрелә.

3.5. Вәкаләтле органның җаваплы вазыйфаи заты көненә кимендә 2 тапкыр ЕПГУдан һәм/яки РПГУдан кергән электрон гаризалар булуны тикшерә.

3.6. Вәкаләтле органның җаваплы вазыйфаи заты тәэмин итә:

- гариза бирелгән вакыттан башлап 1 эш көненнән соңга калмыйча, ә ул эш көне булмаган яки бәйрәм көнне кергән очракта, – аннан соң килгән беренче эш көнендә муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны эш өчен кабул итү. Шул ук вакытта ЕПГУда һәм/яки РПГУда гариза бирүчегә «Гариза карап тикшерелә башлады» дигән белдерү җибәрелә.

Гаризадагы мәгълүматларны раслау кирәк булган очракта, гариза бирүчегә бу хакта ЕПГУда һәм/яки РПГУда «Гаризадагы мәгълүматларны раслау өчен Сезгә Вәкаләтле органга түбәндәге документларны (гариза бирүче тапшырырга тиешле раслаучы документлар исемлеге) тапшырырга кирәк.» дигән белдерү рәвешендә хәбәр ителә. Әлеге җитешсезлекләр, хәбәр ителгән көннән соң 3 эш көне эчендә, гариза бирүче тарафыннан мөстәкыйль рәвештә ЕПГУда һәм/яки РПГУда төзәтелергә мөмкин.

- гаризаны карап тикшерү. Гаризаны карап тикшерүнең арадаш нәтиҗәсе буларак гариза бирүчегә ЕПГУда һәм/яки РПГУда түбәндәге белдерү рәвешендә хәбәр ителә: «Сезнең гариза карап тикшерелде. Гаризаның индивидуаль номеры (номер күрсәтелә). Сайлап алынган белем бирү оешмасына җибәрүне көтегез (гаризада күрсәтелгән кабул итүнең теләнгән датасы күрсәтелә)» (хезмәтнең уңай арадаш нәтиҗәсе) яисә «(гариза буенча тискәре карар кабул ителгән сәбәп күрсәтелә) сәбәпле агымдагы гариза буенча Сезгә хезмәт күрсәтүдән баш тартыла. Сезгә (гариза

бирүчегә гариза буенча уңай нәтиҗә алу өчен үтәргә тиешле гамәлләр тәртибе күрсәтелә) кирәк» (хезмәтнең тискре арадаш нәтиҗәсе).

Гариза бирүче тарафыннан гаризада күрсәтелгән белем бирү оешмаларына кабул итүнең теләгән датасы килеп җиткәч һәм буш урыннар булмаганда (РГИС ДДО мәгълүматлары буенча), гариза бирүчегә ЕПГУда һәм/яки РПГУда «Хәзерге вакытта гаризада күрсәтелгән белем бирү оешмаларында гаризада соралган шартларга туры килә торган буш урыннар юк» дигән белдерү рәвешендә хәбәр ителә. Сезгә (мөмкинлек булганда урыннар бирелергә мөмкин булган белем бирү оешмалары исемлеге күрсәтелә) урын тәкъдим ителергә мөмкин. Әлеге белем бирү оешмасында урын алуга риза булган очракта, Сезгә, җибәрү өчен, кабул итү өчен сайланган мәктәпкәчә белем бирү оешмалары исемлеген гаризада үзгәрергә кирәк.» дигән белдерү рәвешендә хәбәр ителә.

Гариза бирүче гаризада күрсәтелгән белем бирү оешмаларына кабул итүнең теләгән датасы килеп җиткәч һәм буш урыннар булганда (РГИС мәгълүматлары буенча) мәктәпкәчә белем бирү оешмасына җибәрү (төп нәтиҗә) гамәлгә ашырыла. Бала өчен урын билгеләү турындагы мәгълүматны үз эченә алган җибәрү турында документ расланганнан соң һәм әлеге документның реквизитлары РГИСка кертелгәннән соң ЕПГУда һәм/яки РПГУга гариза бирүчегә «Сез (баланы мәктәпкәчә белем бирү оешмасына җибәрү турындагы документның реквизитлары күрсәтелә) нигезендә (мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең номеры) мәктәпкәчә белем бирү оешмасына җибәреләсез. Сезгә (гамәлләрне башкару срогын күрсәтеп, «Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенә җибәрелде» статусы куелганнан соң гариза бирүченең эш тәртибе тасвирлана) кирәк (төп хезмәтнең уңай нәтиҗәсе)».

3.7. Гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен, гариза ЕПГУда бирелгәндә, белдерү рәвешендә ЕПГУда яки гариза РПГУда бирелгәндә, башка формада бирелгән гаризалар турында мәгълүмат алу турында сораганда, белдерү рәвешендә РПГУда, иясе билгесез рәвештә Вәкаләтле орган сайтында яки стендында алу мөмкинлеге тәэмин ителә. Кирәк булганда, гариза бирүче нәтиҗәне шулай ук Вәкаләтле органга шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, җибәрү турындагы документтан өземтә рәвешендә алырга мөмкин.

3.8. Гариза бирү ысулына бәйсез рәвештә, гариза бирүченең запросы буенча аңа гаризаны карап тикшерү барышы турында һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында мәгълүматны ЕПГУда һәм/яки РПГУда алу мөмкинлеге бирелгән.

ЕПГУда хезмәттән файдалану өчен, гариза бирүче ЕСИАда расланган исәп язмасы булган шәхси зат (физик зат) ролендә авторизацияләнергә, «Шәхси кабул итүдә бирелгән гаризалар буенча мәгълүмат алуга язылырга» хезмәте вариантын сайларга, ә аннан соң «Хезмәттән файдалану» төймәсе буенча гаризаның интерактив формасын ачарга, аны тутырырга һәм гариза бирергә тиеш.

3.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатын бәяләү.

Муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфатын бәяләү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гражданнар тарафыннан, муниципаль хезмәтләр күрсәтү сыйфатын исәпкә алып, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары (аларның структур бүлекчәләре) һәм дәүләт бюджеттан тыш фондларның территориаль органнары (аларның региональ бүлекчәләре) җитәкчеләре, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру сыйфатын исәпкә алып, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләр җитәкчелере эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү, шулай ук күрсәтелгән бәяләү нәтиҗәләрен тиешле җитәкчеләр тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәүне вакытыннан алда туктату турында карарлар кабул итү өчен нигез буларак куллану турында» 2012 елның 12 декабрендәге 1284 номерлы карары белән расланган Гражданнар тарафыннан, муниципаль хезмәтләр күрсәтү сыйфатын исәпкә алып, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары (аларның структур

бүлекчәләре) җитәкчеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү, шулай ук күрсәтелгән бәяләү нәтиҗәләрен тиешле җитәкчеләр тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәүне вакытыннан алда туктату турында карарлар кабул итү өчен нигез буларак куллану кагыйдәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.10. Гариза бирүчегә, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 11.2 статьясы нигезендә һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә кылган гамәлләргә (гамәл кылмауга) һәм карарларга судка кадәр, (судтан тыш) шикаять бирү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2012 елның 20 ноябрендәге 1198 номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә, Вәкаләтле органның, Вәкаләтле орган вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең карарларына, гамәлләренә яки гамәл кылмавына шикаятьне бирү мөмкинлеге тәэмин ителә.

### Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә кәгазь рәвештә бирелгән документлардагы хаталарны һәм басмадагы хаталарны төзәтү тәртибе

3.11. Вәкаләтле орган тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә кәгазь рәвештә документлар бирү каралмаган.

## IV. Административ регламент үтәлешен контрольдә тоту формалары

### Җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүгә таләпләрне билгели торган регламент нигезләмәләре һәм башка норматив хокукый актлар үтәлешенә һәм башкарылуга, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул итүгә агымдагы контрольне гамәлгә ашыру тәртибе

4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүгә таләпләрне билгели торган административ регламент, башка норматив хокукый актлар үтәлешенә һәм башкарылуга агыидагы контроль Вәкаләтле органның муниципаль хезмәт күрсәтүгә контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан даими нигездә гамәлгә ашырыла.

Агымдагы контроль өчен хезмәт корреспонденциясе мәгълүматлары, Вәкаләтле орган белгечләренең һәм вазыйфаи затларының телдән һәм язма мәгълүматы кулланыла.

Агымдагы контроль түбәндәгеләргә тикшерү үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла:

муниципаль хезмәтне күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карарлар;

гражданнарның хокукларын бозуларны ачыклау һәм бетерү;

вазыйфаи затларның карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр булган гражданнар мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү, карарлар кабул итү һәм җаваплар әзерләү.

### Муниципаль хезмәт күрсәтү тулылыгын һәм сыйфатын планлы һәм планнан тыш тикшерүләрне гамәлгә ашыру тәртибе һәм вакыты, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтү тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту планлы һәм планнан тыш тикшерүләр үткәрүне үз эченә ала.

4.3. Планлы тикшерүләр Вәкаләтле орган җитәкчесе тарафыннан раслана торган Вәкаләтле органның еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла. Муниципаль хезмәт күрсәтү тулылыгын һәм сыйфатын планлы тикшергәндә түбәндәгеләр контрольдә тотылырга тиеш:

муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын үтәү;
административ регламентның нигезләмәләрен үтәү;
муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында кабул ителгән карарның дөреслеге һәм нигезлелеге.

Планнан тыш тикшерүләр үткәрү өчен нигез булып тора:

дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан Россия Федерациясе норматив хокукый актларының, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актлары фаразланган яисә ачыкланган бозулар турында мәгълүмат, гражданнаргың һәм юридик затларның законнар бозылуга, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфатына карата мөрәҗәгатьләр алу.

Муниципаль хезмәт күрсәтү барышында алар тарафыннан кабул ителә торган (гамәлгә ашырыла торган) карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) өчен вазыйфаи затларның җаваплылыгы

4.4. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча административ регламент нигезләмәләре, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актлары бозылу ачыкланган очракта, гаепле затларны Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тарту гамәлгә ашырыла.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында карар кабул итүнең дөреслеге һәм үз вакытында башкарылуы өчен вазыйфаи затларның шәхси җаваплылыгы законнар таләпләре нигезендә аларның вазыйфаи регламентларында беркетелә.

Муниципаль хезмәт күрсәтүне, шул исәптән гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан контрольдә тоту тәртибенә һәм формаларына таләпләр

4.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалар муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) тәмамлау сроклары турында мәгълүмат алу юлы белән муниципаль хезмәт күрсәтүгә контрольне гамәлгә ашырырга хокуклы.

Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалар шулай ук түбәндәгеләргә хокуклы:

муниципаль хезмәт күрсәтүдән файдалану мөмкинлеген һәм сыйфатны яхшырту буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр җибәрергә;

административ регламентны бозуларны бетерү чаралары турында тәкъдимнәр кертергә.

4.6. Вәкаләтле органның вазыйфаи затлары хокук бозуларны туктату чараларын күрә, хокук бозуларны кылуга китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны бетерә.

Гражданнарның, аларның берләшмәләренең һәм оешмаларның искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен карап тикшерү нәтиҗәләре турында мәгълүмат әлеге искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне җибәргән затларга җиткерелә.

V. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

5.1. Гариза бирүче, муниципаль хезмәт күрсәткәндә Вәкаләтле органның, Вәкаләтле орган вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең, күпфункцияле үзәкнең, шулай ук күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм (яки) гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять (алга таба – шикаять) бирү хокукына ия.

Гариза бирүченең судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә
шикаяте җибәрелергә мөмкин булган җирле үзидарә органнары,
оешмалар һәм шикаятьне карап тикшерүгә вәкаләтле затлар

5.2. Гариза бирүче судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять белән язма рәвештә кәгазь төрдә яки электрон формада мөрәҗәгать итәргә хокуклы:

Вәкаләтле органга – вазыйфаи затның, Вәкаләтле органның структур бүлекчәсе җитәкчесенең карарына һәм (яки) гамәлләренә (гамәл кылмавына), Вәкаләтле органның, Вәкаләтле орган җитәкчесенең карарына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына);

югары органга – вазыйфаи затның, Вәкаләтле органның структур бүлекчәсе җитәкчесенең карарына һәм (яки) гамәлләренә (гамәл кылмавына);

күпфункцияле үзәк җитәкчесенә – күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына);

күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючыга – күпфункцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына).

Вәкаләтле органда, күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючыда шикаятьләрне карап тикшерүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары билгеләнә.

Гариза бирүчеләргә шикаять бирү һәм аларны карап тикшерү тәртибе турында
мәгълүмат бирү ысуллары, шул исәптән ЕПГУдан һәм/яки РПГУдан файдаланып

5.3. Шикаять бирү һәм аны карап тикшерү тәртибе турында мәгълүмат муниципаль хезмәт күрсәтү урыннарында мәгълүмат стендларында, Вәкаләтле орган сайтында, ЕПГУда һәм/ яки РПГУда урнаштырыла, шулай ук телефон аша һәм (яки) шәхси кабул итүдә телдән бирелә яисә гариза бирүче (вәкил) тарафыннан күрсәтелгән адрес буенча почта аша язма рәвештә җибәрелә.

Муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул ителгән карарларга
һәм (яки) гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү
тәртибен җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге

5.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүче Вәкаләтле органның, шулай ук аның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе түбәндәгеләр нигезендә җайга салына:

210-ФЗ номерлы Федераль закон;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә кылган гамәлләргә (гамәл кылмауга) һәм карарларга судка кадәр, (судтан тыш) шикаять бирү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2012 елның 20 ноябрендәге 1198 номерлы карары.

VI. Күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны (гамәлләрне)
башкару үзенчәлекләре

Күпфункцияле үзәкләр тарафыннан башкарыла торган муниципаль хезмәтне
күрсәткәндә административ процедураларның (гамәлләрнең) тулы исемлеге

6.1. Күпфункцияле үзәк гамәлгә ашыра:

- гаризалар кабул итүне:

- балаларны мәктәпкәчә төп белем бирү программасын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү оешмаларына исәпкә куюга;

- баланы мәктәпкәчә төп белем бирү программасын тормышка ашыра торган бер муниципаль белем бирү оешмасыннан (балалар бакчаларыннан) мәктәпкәчә төп белем

бирү программасын тормышка ашыра торган башка муниципаль белем бирү оешмасына күчерү өчен исәпкә куюга;

- мәктәпкәчә төп белем бирү программасын тормышка ашыра торган өстенлекле муниципаль белем бирү оешмасын алмашуга;

- мәктәпкәчә төп белем бирү программасын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү оешмасына җибәрелгәннән соң, «килмәде» статусы алган очракта чиратны торгызуга.

Гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәккә бирелгән гаризаларны теркәү Вәкаләтле орган тарафыннан өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

«Балаларны мәктәпкәчә белем бирү программаларын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү оешмаларына исәпкә кую һәм җибәрү» муниципаль хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта

Муниципаль хезмәтнең (исәпкә кую) арадаш нәтиҗәсен электрон формада бирү турында белдерү кәгазе формасы

Мәгълүмат бирү статусы: Гариза карап тикшерелде

Мәгълүмат бирү статусына комментарий:
«Сезнең гаризагыз карап тикшерелде. Гаризаның индивидуаль номеры ________________. Сайлап алынган белем бирү оешмасына җибәрүне ____________ (гаризада күрсәтелгән, үзегез теләгән кабул итү датасы күрсәтелә) ______________соң көтегез.»

«Балаларны мәктәпкәчә белем бирү программаларын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү оешмаларына исәпкә кую һәм җибәрү» муниципаль хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
2 нче кушымта

Муниципаль хезмәтнең арадаш нәтиҗәсен (кәгазьдә)
бирү турында карар формасы

________________________________________________
Җирле үзидарә органының
вәкаләтле органы исеме

Кемгә: ________________

Исәпкә кую өлешендә «Балаларны мәктәпкәчә белем бирү программаларын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү оешмаларына исәпкә кую һәм җибәрү» муниципаль хезмәте күрсәтү турында
КАРАР

___________ (дата) № ________

Сезнең _____елның _____ ____________ ______________номерлы гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны карап тикшергәннән соң

__________________________________________________________________
(вәкаләтле органның исеме)
вәкаләтле орган тарафыннан карар кабул ителде: _________________________________ (баланың Ф.И.А.и. тулысынча)
дәүләт (муниципаль) белем бирү оешмасында урын бирүгә мохтаҗ сыйфатында исәпкә куярга (гаризада күрсәтелгән параметрларны санап чыгарга).

________________________________ Хезмәткәрнең вазыйфасы һәм Ф.И.А.и.

«Балаларны мәктәпкәчә белем бирү программаларын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү оешмаларына исәпкә кую һәм җибәрү» муниципаль хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
3 нче кушымта

Муниципаль хезмәтне (муниципаль белем бирү
оешмасына җибәрү) электрон формада бирү турында
белдерү кәгазе формасы

Мәгълүмат бирү статусы: *Муниципаль белем бирү оешмасына җибәрелде*

Мәгълүмат бирү статусына комментарий:

Сезгә _________________________ нигезендә (баланы мәктәпкәчә белем бирү оешмасына җибәрү турында документт реквизитлары күрсәтелә) ______________________________ (мәктәпкәчә белем бирү оешмасының исеме, төркем турында мәгълүматлар күрсәтелә) урын бирелде.

Сезгә түбәндәгеләрне башкарарга кирәк _____________ (статус куелганнан соң, гамәлне башкару срогын күрсәтеп, гариза бирүченең эш итү тәртибе тасвирлана).»

«Балаларны мәктәпкәчә белем бирү программаларын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү оешмаларына исәпкә кую һәм җибәрү» муниципаль хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
4 нче кушымта

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында карар формасы
(кәгазьдә)

_______________________________________________

Җирле үзидарә органының
вәкаләтле органы исеме

Кемгә: ________________

Муниципаль белем бирү оешмасына җибәрү өлешендә
«Балаларны мәктәпкәчә белем бирү программаларын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү оешмаларына исәпкә кую һәм җибәрү»
муниципаль хезмәте күрсәтү турында
КАРАР (кәгазьдә)

___________ (дата) № ________

Сезгә________________________ (баланы мәктәпкәчә белем бирү оешмасына җибәрү турында документ реквизитлары күрсәтелә) нигезендә, ____________ телдә (белем бирүнең тиешле теле күрсәтелә) белем бирү программасы буенча укыту өчен (белем бирү программасының исеме һәм юнәлеше күрсәтелә (булганда)/ карау һәм тәрбияләүне гамәлгә ашыру өчен), _______________төркемдә (компенсацияләү һәм катнаш юнәлешле төркемнәр өчен төркемнең төрен һәм сәламәтләндерү төркемнәре өчен төркемнең профилен күрсәтеп юнәлеше, төркемнең яшь күрсәткече) __________ режимы белән (баланың төркемдә булу режимы күрсәтелә) ____________________________ (мәктәпкәчә белем бирү оешмасының исеме, төркем турында мәгълүматлар күрсәтелә) урын бирелде.

Сезгә түбәндәгеләрне башкарарга кирәк ____________ (гамәлне башкару срогын күрсәтеп, гариза бирүченең эш итү тәртибе тасвирлана).

_______________________________ Хезмәткәрнең вазыйфасы һәм Ф.И.А.и.

«Балаларны мәктәпкәчә белем бирү программаларын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү оешмаларына исәпкә кую һәм җибәрү» муниципаль хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
5 нче кушымта

Муниципаль хезмәтнең (исәпкә кую) арадаш нәтиҗәсен электрон формада бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазенең формасы

Мәгълүмат бирү статусы: Хезмәт күрсәтүдән баш тартылды

Мәгълүмат бирү статусына комментарий:
Сезгә агымдагы гариза буенча ______________________сәбәп буенча (гариза буенча тискәре карар кабул ителүнең сәбәбәбе күрсәтелә) хезмәт күрсәтүдән баш тартыла.
Сезгә түбәндәгеләрне башкарарга кирәк ____________ (гариза буенча уңай нәтиҗә алу өчен гариза бирүче башкарырга тиешле гамәлләрнең тәртибе күрсәтелә).

«Балаларны мәктәпкәчә белем бирү программаларын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү оешмаларына исәпкә кую һәм җибәрү» муниципаль хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
6 нчы кушымта

Муниципаль хезмәтнең арадаш нәтиҗәсен (кәгазьдә) бирүдән баш тарту турында карар формасы

___________________________________________________

Җирле үзидарә органының
вәкаләтле органы исеме

Кемгә: ________________

Исәпкә кую өлешендә «Балаларны мәктәпкәчә белем бирү программаларын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү оешмаларына исәпкә кую һәм җибәрү» муниципаль хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында
КАРАР

___________ (дата) № ________

Сезгә агымдагы гариза буенча ______________________сәбәп буенча (гариза буенча тискәре карар кабул ителүнең сәбәбе күрсәтелә) хезмәт күрсәтүдән баш тартыла.

Сезгә түбәндәгеләрне башкарарга кирәк ____________ (гариза буенча уңай нәтиҗә алу өчен гариза бирүче башкарырга тиешле гамәлләрнең тәртибе күрсәтелә).

___________________ Карарны кабул иткән хезмәткәрнең вазыйфасы һәм Ф.И.А.и.

«Балаларны мәктәпкәчә белем бирү программаларын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү оешмаларына исәпкә кую һәм җибәрү» муниципаль хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
7 нче кушымта

Муниципаль хезмәтне электрон рәвештә күрсәтү турында гариза формасы

______________________________________________________________

(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы булганда),
шәхесне раслаучы документ, элемтә өчен телефон,
почта адресы, электрон почта адресы)

Муниципаль хезмәтне электрон рәвештә күрсәтү турында
ГАРИЗА

<table>
<tr><th>№ т/ б</th><th>Сораулар исемлеге</th><th colspan="2">Җаваплар</th></tr>
<tr><td>1</td><td>Сез баланың ата-анасымы яки законлы вәкилеме</td><td>Ата-анасы</td><td>Законлы вәкил</td></tr>
<tr><td colspan="4">ЕСИАдан файдаланучының профилендәге мәгълүмат автоматик рәвештә тутырыла:<br>фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда);<br>паспорт мәгълүматлары (сериясе, номеры, кем тарафыннан, кайчан бирелгән)<br>Әгәр ЗАКОНЛЫ ВӘКИЛ булса, электрон рәвештә өстәмә бала хокукларын яклауны раслаучы документ (лар) бирелергә мөмкин.<br>Өстәмә рәвештә ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) элемтә мәгълүматлары (телефон, электрон почта адресы (булганда)) бирелә.</td></tr>
<tr><td></td><td colspan="3">Хезмәт күрсәтү турында гариза бирелә торган баланың шәхси мәгълүматлары:<br>Фамилия, исеме, атасының исеме (булганда); туган көне; баланың туу турында таныклыгының яки баланың шәхесен раслаучы башка документ реквизитлары; яшәү урыны адресы.</td></tr>
<tr><td></td><td colspan="3">ЕСИАдан гариза бирүченең профилендәге бала турында мәгълүмат булганда, мәгълүматлар автоматик рәвештә тутырыла</td></tr>
<tr><td></td><td colspan="3">Кабул итүнең үзең теләгән параметрлары: үзең теләгән кабул итү датасы;<br>белем бирү теле (исемлектән сайлау); төркемдә баланың тору режимы (исемлектән сайлау); төркемнең юнәлеше (исемлектән сайлау);<br>Компенсацияләү төркеме төре (компенсацияләү юнәлеше төркемнәрен сайлаганда исемлектән сайлау);<br>Адаптацияләнгән программа буенча (булганда) укыту ихтыяҗын раслаучы документ реквизитлары;</td></tr>
</table>

| | | |
|---|---|---|
| | *Сәламәтлек төркеменең профиле (сәламәтләндерү юнәлешендәге төркемнәрне сайлаганда исемлектән сайлау)*<br>*Сәламәтләндерү төркеменә ихтыяҗны раслаучы документ реквизитлары (булганда).*<br>Сәламәтләндерү яисә компенсацияләү төркемен сайлаган очракта, өстәмә электрон рәвештә аны биргән оешманың көчәйтелгән квалификацияле имзасы белән расланган тиешле документ бирелергә мөмкин; психологик-медицина-педагогик комиссия бәяләмәсенең реквизитлары (кирәк булганда). Өстәмә электрон рәвештә аны биргән оешманың көчәйтелгән квалификацияле имзасы белән расланган тиешле документ бирелергә мөмкин;<br>Кабул итү өчен белем бирү оешмалары (сайлап алу буенча, әлеге Административ регламентка кушымта нигезендә, территорияләрне билгеле бер белем бирү оешмаларына беркетү нигезендә бирелә) | |
| 2 | Кабул итү өчен сайлап алынган мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының исемлеге (административ регламентка 11 нче кушымта) | Килешүләр, шул исәптән дәүләт-шәхси, муниципаль-шәхси партнерлык турында килешүләр кысаларында муниципаль берәмлектәге баланың яшәү адресына караган дәүләт, муниципаль белем бирү оешмалары, шулай ук башка оешмалар исемлегеннән (исемлек региональ мәгълүмат системаларында формалаштырыла) сайлап алу мөмкинлеге, сайлап алынган мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының өстенлек тәртибен күрсәтеп; сайлап алына торган мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының максималь саны мәгариф өлкәсендәге идарә органы тарафыннан билгеләнә |
| 3 | Сайланган мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында урыннар булмаса, кабул итү өчен сайланган мәктәпкәчә белем бирү оешмалары исемлегеннән тыш башка мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына җибәрүгә ризалык | «Әйе/Юк» бинар тамгасы, әйтелмәгәндә – «Юк» |
| | Гомумүстерешле төркемгә ризалык | «Әйе/Юк» бинар тамгасы гомумүстерешле юнәлешле булмаган төркемне сайлаганда тутырылырга мөмкин, әйтелмәгәндә– «Юк» |
| | Карау һәм тәрбияләү төркеменә ризалык | «Әйе/Юк» бинар тамгасы, әйтелмәгәндә – «Юк» |
| | Кыска вакытлы режимга ризалык | «Әйе/Юк» бинар тамгасы, әйтелмәгәндә – «Юк», кыска вакытлы режим көнгә 5 сәгатьтән артык булу режимын сайлаганда тутырылырга мөмкин |
| | Тулы көн төркеменә ризалык | «Әйе/Юк» бинар тамгасы, әйтелмәгәндә – «Юк», тулы көн режимыннан аерылып торучы төркемне сайлаганда тутырыла |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4. | Сезнең башка балаларыгыз (урын кирәк булган баланың кабул итү өчен сайлап алынган белем бирү оешмаларында укучы ир туганнары, кыз туганнары) бармы | Әйе | Юк |
| Әйе икән, аларның Ф.И.А.и., алар укыган оешманың исемен күрсәтегез. Юк икән, 5 нче сорауга күчәргә кирәк. | | | |
| 5. | Сезнең махсус ярдәм чараларына хокукыгыз бармы (чираттан тыш яки беренче чиратта кабул итү) | Әйе | Юк |
| Электрон рәвештә өстәмә аны биргән оешманың көчәйтелгән квалификацияле имзасы белән расланган тиешле документ бирелергә мөмкин. | | | |

«Балаларны мәктәпкәчә белем бирү программаларын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү оешмаларына исәпкә кую һәм җибәрү» муниципаль хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
8 нче кушымта

Дәүләт (муниципаль)
хезмәте күрсәтү турында кәгазьдәге
ГАРИЗА

Мин, (ата-ананың (законлы вәкилнең) Ф.И.А.и., паспорт мәгълүматлары (вәкиллекне раслаучы документ реквизитлары), ата - ана буларак, муниципаль белем бирү оешмасында белем бирү оешмасында урын бирелүгә мохтаҗ буларак исәпкә куюны, шулай ук укыту мөмкинлеге биреп (белем бирү телен, баланың төркемдә булу режимын, төркемнең юнәлешен, психологик-медицина-педагогик комиссия (булган очракта) бәяләмәсенең реквизитларын күрсәтеп),(баланың Ф.И.А.и, туган көне, туу турында таныклык (шәхесне раслаучы документ) реквизитлары, яшәү урыны адресы) муниципаль белем бирү оешмасына (белем бирү оешмасының исеме) укырга җибәрүне (укытуның үзең теләгән датасы) сорыйм.

Күрсәтелгән белем бирү оешмасында кабул итү өчен урыннар булмаганда, исемлек буенча түбәндәге белем бирү оешмаларын укырга җибәрүегезне сорыйм (өстенлекле тәртиптә күрсәтелә).

Миңа тиешле ярдәм чаралары белән бәйле рәвештә (чираттан тыш яки беренче чиратка кабул итү хокукы) әлеге хезмәтне чираттан тыш (беренче чиратта) күрсәтүегезне сорыйм. Хокукны раслаучы тиешле документлар беркетелә.

Белем бирү оешмасында (өстенлекле итеп күрсәтелгән белем бирү оешмасының исеме) баланың (гариза бирелә торган баланың Ф.И.А.и. күрсәтелә) ир туганы/кыз туганы укый (туганының Ф.И.А.и. күрсәтелә).

Элемтә мәгълүматлары: ата-анасының (законлы вәкилләрнең) телефон номеры, электрон почта адресы (булганда).

Кушымта:

______________________________________________________________________.
гариза бирүче биргән документлар

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында миңа хәбәр итүегезне сорыйм:
телефон аша: _____________; почта адресы буенча: _________________;
электрон почта адресы буенча: ______; КФҮ аша: _________________.
(кирәклесен язарга)

_______________________________________________________
(гариза бирүче) (имза)

Дата: «_____» ________ 20_ ел.

«Балаларны мәктәпкәчә белем бирү программаларын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү оешмаларына исәпкә кую һәм җибәрү» муниципаль хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
9 нчы кушымта

Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар формасы

________________________________________________

Җирле үзидарә органының
вәкаләтле органы исеме

Кемгә: ____________

«Балаларны мәктәпкәчә белем бирү программаларын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү оешмаларына исәпкә кую һәм җибәрү» муниципаль хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында

КАРАР

___________ (дата) № ________

Сезнең 20___ елның _____ __________ ______номерлы гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны карап тикшергәннән соң ______________________________(Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимияте вәкаләтле органының исеме) түбәндәге нигезләр буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителде:

| Административ регламент пунктының № | Стандарт нигезендә баш тарту өчен нигезнең исеме | Документларны кабул итүдән һәм теркәүдән баш тартуның сәбәпләрен аңлату [1] |
| --- | --- | --- |

Өстәмә мәгълүмат: ________________________________________.

Күрсәтелгән кимчелекләрне бетергәннән соң Сез муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза белән вәкаләтле органга кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Әлеге баш тартуга шикаятьне вәкаләтле органга җибәрү юлы белән судка кадәр тәртиптә, шулай ук суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.

_____________ Электрон имза турында мәгълүматлар

_______________________ Карар кабул иткән хезмәткәрнең вазыйфасы һәм Ф.И.А.и.

_________________________

«Балаларны мәктәпкәчә белем бирү программаларын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү оешмаларына исәпкә кую һәм җибәрү» муниципаль хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
10 нчы кушымта

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары

| Административ процедураны башлау өчен нигез | Административ гамәлләрнең эчтәлеге | Административ гамәлләрнең сроклары | Административ гамәлне башкару өчен җаваплы вазыйфаи зат | Административ гамәлне башкару урыны | Карар кабул итү критерийлары | Административ гамәлнең нәтиҗәсе, фиксацияләү ысулы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. Гаризаны кабул итү һәм теркәү | | | | | | |
| Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документларның вәкаләтле органга керүе | Документларны кабул итү һәм аларның тулылыгын документларны кабул итү өчен административ регламентның 2.12 пункты белән каралган нигезләр булуга/ булмауга тикшерү Гариза бирүчегә документларны кабул итү өчен административ регламентның 2.12 пункты белән каралган нигезләр булу турында хәбәр итү (гариза кәгазьдә кергәндә) | 1 көн | Вәкаләтле органның җаваплы вазыйфи заты | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Гаризадагы мәгълүматларны туу турында таныклыкның яки баланың шәхесен раслаучы документның (сериясе, документ номеры һәм туган көне) мәгълүматлары буенча кабатланган мәгълүмат булуга тикшерү. Тикшерү уңай булганда «Гариза карап тикшерүгә кабул ителде» дигән мәгълүмат бирү статусы формалаштырыла, кабатланган мәгълүмат булганда, баш тарту сәбәбен күрсәтеп, «Хезмәт күрсәтүдән баш тартыла» дигән мәгълүмат бирү статусы формалаштырыла. (гаризаны электрон формада кергәндә) | 1 көн | | | | |
| | Күрсәтелгән вакыт эчендә кирәкле документлар (документлардан мәгълүматлар) тапшырылмаган, ачыкланган кимчелекләр төзәтелмәгән очракта, гариза бирүчегә кәгазьдә бирелгән гаризада күрсәтелгән ысуллар белән баш тартуның сәбәпләрен күрсәтеп, баш тарту турында белдерү кәгазен формалаштыру һәм җибәрү | Кабул иткән һәм комплектлылыкны тикшергән көнне | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | административ регламентның 2.12 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен, шулай ук исәпкә кую рәвешендә арадаш нәтиҗә өлешендә хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, документларны исәпкә алу буенча электрон мәгълүмат базасында гаризаны теркәү | Кабул иткән һәм комплектлылыкны тикшергән көнне | | | | |
| 2.Мәгълүматны СМЭВ аша алу | | | | | | |
